РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024 г. г. Альметьевск № 297

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын күтәрү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында»гы (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 30 октябрендәге 9 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 137 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 167 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 172 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 187 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 3 пунктындагы 3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарның 7 һәм 10 пунктларында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палаталары» сүзләрен «Әлмәт муниципаль районының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районының бюджет өлкәсе җитәкчеләренең һәм белгечләрнең вазыйфаи окладлары күләме, бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре каралмый

| «Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 18 120 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 17 587 |
| Бүлек башлыгы | 16 921 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 16 121 |
| Баш белгеч | 15 322 |
| Әйдәп баручы белгеч | 14 523 |
| I категорияле белгеч | 13 590 |
| II категорияле белгеч | 13 457 |
| Белгеч | 13 323» |

1.4. 2 нче кушымта таблицасында «12 688» санын «13 323» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА